| СОВЕТ КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 22 ноябре** **№ 178**

Күгәй авылы

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Күгәй авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.
3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру Күгәй авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына ел саен бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.
4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2024 елның 9 апрелендәге 151 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урам, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык ур., 20 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Күгәй авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф.Х.Хисәметдинова